**КАРАР**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы

Әтрәкле авыл җирлеге Советы

Атрякле авылы

№ 1 «25» сентябрь 2018 ел

**Әтрәкле авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы №23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 18 маддәсе, “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсе, “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге” Башкарма комитетының 2018 елның 18 сентябрендәге №78 карары һәм “Референдум үткәрү турында” Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 сентябрендәге карары нигезендә

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРА:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:
"Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2019 елда 500 сум үзара салым кертүгә сез, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарының тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтүгә килешәсезме:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

- Әтрәкле, Калтак, Татар Мөшегесе, Яңа Айман, Чупай,Филимоновка торак пунктында янгын гидрантлары урнаштыру;

- Әтрәкле, Калтак, Татар Мөшегесе, Яңа Айман, Чупай,Филимоновка торак пунктындагы янгын гидрантларына күрсәткечләр әзерләү һәм урнаштыру.

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Әтрәкле, Калтак,Татар Мөшегесе торак пунктларында уен мәйданчыклары сатып алу һәм монтажлау;

- Әтрәкле, Калтак, Татар Мөшегесе, Яңа Айман, Чупай,Филимоновка, Рус Мөшегесе урамнарын яктырту һәм ремонтлау;

- төзелеш материаллары сатып алу һәм Рус Мөшегесе һәм Чупай торак пунктларында җәяүлеләр күперләрен агымдагы ремонтлау.

3. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:

- Әтрәкле, Калтак, Татар Мөшегесе, Яңа Айман, Чупай,Филимоновка авылларында су челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау.

4. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:

- Рус Мөшегесе торак пунктында зират өчен инвентарь сатып алу.

"ӘЙЕ" "ЮК".

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Минзәлә муниципаль районының menselinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы Газизҗанов Рөстәм Шакирҗановичка йөкләргә.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы: Р. Ш. Газизҗанов